# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте авылында

2023 елның 16 ноябре, №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте авылында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда авыл җирлегендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте авылында, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урыны буенча өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем Инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергән яки контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән, бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән (СВО катнашучылар)дан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Тукай һәм Мәктәп урамнарында гидрантлар урнаштыру;
- кышкы вакытта Яңа Чүте авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм тоту.

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә), Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга ( http://bavly.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче З. С. Галләметдинов